**МИНИСТЕРСТВО ПРОСВЕЩЕНИЯ РОССИЙСКОЙ ФЕДЕРАЦИИ**

**Министерство образования и науки Республики Татарстан**

**Актанышский муниципальный район**

**Сафаровская СОШ**

| РАССМОТРЕНО | СОГЛАСОВАНО | УТВЕРЖДЕНО |
|---|---|---|
| Руководитель ШМО | Зам.директора УВР | Директор школы |
| ___________Галимова Г.О. | ____________ Закирова Л.Я. | ___________Нургалиев А.А. |
| Протокол №1<br>от «25» августа 2023 г. | «29» августа 2023 г. | Приказ №2<br>от «29» августа 2023 г. |

ДОКУМЕНТ ПОДПИСАН ЭЛЕКТРОННОЙ ПОДПИСЬЮ

СВЕДЕНИЯ О СЕРТИФИКАТЕ ЭП

Сертификат: 6838C10C0B27A03BBDBB0A46C119ABDA

Владелец: Нургалиев Ахсан Азгарович

Действителен с 07.12.2022 до 01.03.2024

**РАБОЧАЯ ПРОГРАММА**

**учебного предмета «Литературное чтение на родном (татарском) языке»**

для обучающихся 1 – 4 классов

**с. Старое Сафарово 2023**

**Аңлатма язуы**

**1 нче сыйныф программасы эчтәлеге.(34 сәг.)**

Балалар Әлифбадан әдәби укуга сиздермичә генә, эзлекле рәвештә күчәргә тиеш. Кече яшьтәге мәктәп балалары аңлап укуның беренчел күнекмәләрен ала, халык авыз иҗатының жанрлары белән таныша һәм аларны тормышта кулланырга өйрәнә. Аптыраткыч-алдавыч, әйләнмәле, чылбыр әкиятләрнең сюжет-композиция үзенчәлекләрен аера, авторларның чәчмә һәм шигъри текстлары белән таныша. Халык авыз иҗаты һәм шагыйрьләрнең шигъри әсәрләре аша, юл ахырындагы охшаш сүзләргә нигезләнеп, рифма, кабатлаулар, сәнгатьлелек турында беренчел кузаллау булдырыла.

Кыска текстлар һәм аларга ясалган иллюстрацияләрне чагыштырып, әдәби образның сәнгатьнең төрле төрләрендә тасвирлануы аңлатыла.

Беренче сыйныфны тәмамлаганда бала текстны аңлап укырга һәм аның эчтәлеге буенча үз фикерләрен әйтә белергә тиеш (дәреслектә бирелгән конкрет сорауларга җавап бирү формасында).

Балаларда халык авыз иҗаты турында гомуми күзаллау булдырыла, алар проза һәм поэзиянең үзенчәлекләрен танып беләләр, “автор”, “әсәрнең исеме” төшенчәләре бирелә, әсәрдәге персонажларны танып әйтә алалар.

Беренче сыйныфтагы төп бурыч — укуга кызыксыну тәрбияләү һәм дөрес уку күнекмәләре булдыру — икенче сыйныф өчен дә актуаль булып кала.

Укучыларның уку күнекмәләрен үстерү максатыннан, әдәби уку - укыту методик комплекты дәреслек, мөстәкыйль эш дәфтәре һәм хрестоматия белән тулыландырылган. Бер дәрестә ике ярдәмлек белән эшләргә мөмкин: дәреслек + мөстәкыйль эш дәфтәре яисә дәреслек + хрестоматия. Сыйныфтагы укучыларның белем дәрәҗәсенә карап, бер дәрестә өч ярдәмлекне дә кулланып була. Әдәби уку дәресе күпчелек очракта сүзләр уку белән башланып китә (мөстәкыйль эш дәфтәренең 1-2 нче биремнәре). Дәфтәрдә бирелгән текстлар өстендә эшләү сыйныфта өстәмә материал буларак кулланыла. Дәреслектәге автор текстын һәм әдәби әсәрләрне укытучы яисә яхшы укучы бала укый ала.

Хрестоматиядә бирелгән әсәрләр өстәмә материал булып тора:

а) әгәр укыту планында өстәмә сәгатьләр бирелсә;

ә) Әлифба китабы планлаштырылганнан алданрак өйрәнелеп бетсә;

в) мәктәп китапханәсендә балалар әдәбияты фонды аз яисә искергән булса, шулай ук җәйге ял вакытында да укырга тәкъдим итәргә була.

Хрестоматия күпсанлы укытучылар теләген исәпкә алып төзелде.

Әлифба китабы февраль уртасында яки аннан алдарак беткән очрак өчен планлаштыруда берләштерелгән дәрес эшкәртмәләре бирелде. Мәсәлән, 2—3нче дәресләр итеп “Аптыраткыч әкиятләр законы” бирелгән. Укытучы балаларның үзләштерүләренә карап 1 дәрес итеп тә, 2 дәрес итеп тә үткәрә ала. Мөстәкыйль эш дәфтәрендәге рәсемнәр буяу өчен дә кулланыла.

Укытучыларга ярдәм йөзеннән методик ярдәмлеккә өстәмә рәвештә дәресләргә презентацияләр белән диск эшләнелде. Биредә дәрес өчен кирәкле барлык материалны табарга мөмкин.(музыка, җырлар, картина, рәсемнәр,схема, таблицалар һ.б.)

## 2 нче сыйныф

Әдәби уку дәресләре программасы (34 сәг)

**Халык авыз иҗаты**

**Хайваннар турында әкиятләр.** Әкиятләр турында гомуми кузаллау. Татар халык әкиятләрендәге төп герой белән башка халыклар әкиятләрендәге төп герой арасындагы охшаш һәм аермалы яклар. Геройларның характеры. Россия халыклары әкиятләре.

**Тылсымлы әкиятләр.** Җирдәге һәм тылсымлы дөньяны чагыштыру. Тылсымлы предметлар, (эченнән гаскәр чыга торган таяк,төрле ашамлыклар тулы тырыс, хәзинәсе бер дә кимеми торган сумка, кеше  күзенә күрсәтми торган бүрек, җилән, зур атлата торган итек, дошманны кырып сала торган кылыч һ. б., герой куллана торган тылсымлы әйберләр: тарак, көзге, кайрак, балдак. Тылсымлы булышчылар ( җәнлекләр: әтәч, бүре, аю, куян, убырлы карчык, һ.б.), тылсымлы төсләр (ак һәм кара). Борынгы дөньяның тылсымлы әкиятләрдә чагылышы (табигать көчләре, кешеләрнең хайваннарга, үсемлекләргә әверелеше).

Тылсымлы әкиятләрнең төзелеше (вакыйгаларның чылбыр рәвешендә баруы, кабатланулар, билгеле бер ритм, әкиятне истә калдыру).

**Автор әсәрләре**

Шигъри формада язылган тылсымлы әкиятләр (Г. Тукай “Кәҗә белән сарык әкияте”), аның халык әкиятләре белән охшашлыгы, сюжет һәм композиция үзенчәлеге. Капма-каршы  ике төрле дөнья бирелеше ( җирдәге һәм тылсымлы, тылсымлы булышчылар, тылсымлы әйберләр, тылсымлы төсләр). Автор теленең кабатланмас матурлыгы. Халык авыз иҗаты белән охшашлык (кабатланулар, вакыйгалар бергәлеге һ.б.)

**Хикәя жанры.** ( А. Әхмәт, Г. Ибраһимов, И. Туктар, Л.Лерон,Ә Моталлапов, Э. Шәрифуллина).Жанр үзенчәлекләре: сурәтләнгән вакыйгаларның тормышчанлыгы; әхлакый проблемаларның актуальлеге; уйдырмалар. Хикәянең  төп мәгънәсе. Хикәя исеменең эчтәлеккә туры килүе. Хикәя геройлары, аларның портретлары һәм характерларының сөйләмнәре, башкарган гамәлләре аша чагылышы. Авторның үз героена мөнәсәбәте.

**Шигърият**

Кеше һәм табигать бергәлеге. Дөньяны шагыйрь күзлегеннән чыгып кузаллау. Әйләнә-тирә дөньяның матурлыгы — шагыйрь өчен илһам чишмәсе булуга инандыру. Шигырьдә чагыштыру, сынландыру, эпитет.  Автор әсәрләрендә һәм халык авыз иҗатында охшашлык .Чагыштыру, контраст,, җанландыру кебек гади әдәби алымнарны таба белү. Җанлы сөйләмнең мөһим чараларын  үзләштерү күнегүләре: темп,тавыш көче.. тон, сөйләм мелодикасы (тавышны күтәрү, түбәнәйтү)

**Библиографик культура формалаштыру.**

“Эчтәлек ” белән танышу , аңа карап, кирәкле әсәрне китаптан таба белү, кече яшьтәге мәктәп баласының дәреслектән тыш эшчәнлеген оештыру: өй, мәктәп китапханәләреннән файдалану. Фән буенча сүзлек, белешмә әдәбият, вакытлы матбугат белән эшләү.Балалар китабы белән эшләү. Китапның төп төп элементларын аеру: китап тышлыгы, китап төпсәсе, битләре. Китапны саклап тоту күнекмәләре булдыру.

**Уку, сөйләү, тыңлау күнекмәләре формалаштыру**

Сәнгатьле уку күнекмәләре формалаштыру (интонация, тон, темп саклап кычкырып уку) Автор бирергә теләгән картинаны күзаллау. Эчтән укый белергә күнектерү. Чылбыр рәвешендә укыганда үз урыныңны белеп , чират буенча уку.Укылган әсәргә анализ ясау.

**2 нче сыйныфны тәмамлаганда укучыларның белеменә, эш осталыгына, һәм күнекмәләренә таләпләр.**

-әсәрне сүзләрне дөрес әйтеп кычкырып һәм эчтән укый белү;
-шигырьләрне сәнгатьле итеп уку;
-әсәрнең мәгънәви кисәкләре арасындагы бәйләнешләрне ачыклау, төп фикерне билгеләү һәм аны үз сүзләрең белән әйтеп бирү;

-төрле авторларның 6-8 шигырен яттан сөйләү;
-кыска күләмле әсәрләрнең эчтәлеген сөйләү;
тылсымлы һәм хайваннар турындагы әкиятләрне аера белү;
-әсәрдәге төп геройга мөнәсәбәт белдерү;
укылган әсәрдән чагыштыру, җанландыру,контрастны таба белү;
сүзлекләрдән файдалану;

**Укучы белергә тиеш:**

-2-3 татар классигының исемен;
- 2-3 хәзерге заман язучы яки шагыйренең исемен, алар язган әсәрләрне һәм эчтәлеген;
-үзенә иң ошаган авторның берничә әсәрен.

**Алынган белемнәрне көндәлек тормышта куллану.**

-китапның төрле элементларына карап эчтәлеген билгеләү;
-мөстәкыйль рәвештә уку өчен китап сайлау;
-сүзлекләрдән кирәкле мәгълүматны табу;

**“Әдәби уку”дәреслегенә методик аңлатмалар. 2 сыйныф**

**Искәрмәләр**

**1.Аңлатмалы сүзлек** һәр дәреслекнең, дәреслек-хрестоматиянең һәм мөстәкыйль эш дәфтәренең ахырында бирелә.

2.“**Музей йорты”**на сәяхәт вакытында укучыларның сөйләм телләрен, күзәтүчәнлекләрен, матурлыкка соклана белү хисләрен, гади генә предметны да образ итеп күрә белүләренә ирешергә кирәк.

3.Мөстәкыйль эш дәфтәре белән эш вакытында укучы сары һәм зәңгәр **төсле карандашлар** белән эш итә (фломастерлар белән түгел).

4. Әдәби уку дәресләренең кайберләрендә,”Музей йортына ” сәяхәт вакытында сәнгать әсәрләренең аерым детальләрен яхшылап күзәтү өчен, **лупа** кулланыла.

5.“Музей йорты” белән танышкан вакытта, картиналардан аеруча әһәмиятле фрагментларны кадрлап аерып алу һәм аларны бербөтен итеп карау өчен билгеле бер размердагы рамкалар  файдаланыла. Бу рамкаларны технология дәресләрендә картоннан яисә калын кәгазьдән ясарга мөмкин. Рамканың соргылт, яшел, караңгы төстә булуы мөһим (ак төстә түгел). Рамка 6 см х 9 см зурлыкта була һәм һәр яктан 1,5 см поля калдырыла.

6. Дәрес өчен материал күп бирелде,  Көчле укучылар белән эш оештыру өчен укытучының барлык мөмкинлекләре дә бар. Һәрбер чыганакта да (дәреслек, хрестоматия, мөстәкыйль эш дәфтәре) җитәрлек әсәрләр сайланды. Укытучы өстәмә әсәрләр эзләп мәшәкатьләнмәсә дә була. Күрсәтелгән барлык материалларны эшләп бетерү мәҗбүри түгел, сыйныфның хәзерлек дәрәҗәсенә карап, укытучы үзе сайлап ала. Дәрестә бирелгән материал күп дип уйлаганда мөстәкыйль эш дәфтәрендәге биремнәрне калдырып,материал аз дип уйланган дәресләргә өстәсәң, яисә өй эше итеп төрле хәзерлектәге укучыларга сайлап бирсәң  дә була.

7. Мөстәкыйль эш дәфтәрендә бирелгән рәсемнәрне укучы үзе теләгәнчә буйый ала.

**Укыту методик комплектының бурычлары**

Әдәби уку укыту методик комплекты түбәндәге мәсьәләләрне хәл итә:

1) “Перспектив башлангыч мәктәп” комплекты чишәргә тиешле гомумдидактик бурычлар: укучы үзенә кирәкле информацияне “Эчтәлек” битенә карап таба белергә; исеме буенча текстның эчтәлеген кузалларга; күзәтү эшчәнлеген формалаштырырга (әдәби һәм сәнгать әсәрләреннән аерым детальләрне таба, барлык ваклыклары белән сөйләп бирә) һәм гомумиләштерергә (аерым детальләргә нигезләнеп таралган төрле мәгълүматларны берләштереп, бербөтен картина тудырырга); “акыллы өлкәннәр” белән хат аша аралашу ихтыяҗы формалаштырга.
2) Бала яшенә туры килә торган теоретик бурычлар:

а) хайваннар турындагы әкият үзенчәлекләре белән таныштыру: татар халык әкиятләренең, бер яктан, башка халыкларның хайваннар турындагы әкиятләренә охшаш булуы (төп геройлары — хайваннар, еш кына бер үк төрле мөнәсәбәтләргә керәләр), икенче яктан бер-берсеннән аерылалар (төп геройлар башка төрле хайваннар, бер-берсе белән мөнәсәбәтләре бөтенләй башка төрле); хайваннар турындагы автор әкиятләренең еш кына халык әкиятләренә нигезләнүе (башлангыч сыйныфларда әле автор әкиятләренә нигезләнүе термин буларак әйтелми); халык әкиятләрендә аерым хайваннарның патшалык итүе (баш булуы); хайваннар турындагы әкият героеның һәрвакыт көчсезләрне яклаучы гына түгел, еш кына хәйләкәр, тиктормас, көлкегә калучы икәнлеге турында төшенчә бирү;

ә) тылсымлы әкиятләрнең кайбер үзенчәлекләре белән таныштыру(маҗаралы хәлләрнең, тылсымлы предметлар яки ярдәмчеләрнең булуы, әкияттә кабатлауларның булуы);

б) әхлакый бурычлар:

күзәтүчәнлек, хыяллана белүчәнлек, дуслар белн аралашу, ярата һәм яратыла белү — бу байлык һәм рухи кыйммәт икәнлеге турында кузаллау булдыру;

в) эстетик бурычлар:

матурлык — ул сине чолгап алган тирәлек, бары тик аны күрә белергә кирәклеге турында төшенчә бирү;

г)сөйләм телен үстерү бурычлары:

текстта ориентлаша белергә өйрәтү: бүлекләрне өлешләргә бүлү, кирәк урынны табып укып күрсәтү, хисләр белән белдерелгән өзекнең эчтәлеген ачыклау; әдәби әсәрләргә бәя биргәндә һәм сәнгать әсәрләрен караганда “синең” предметка карашың һәм бәяң – бу “синең” әсәрне аңлау идеяң икәнен җайлап төшендерү.

Дәреслек һәм дәреслек-хрестоматия структурасы һәм идея эчтәлеге буенча бер-берсенә бәйләнеп килә. Мәсәлән, дәреслекнең “Белдекле Керпедә кунакта”, “Белмәмештә кунакта”, “Укымышлы Ябалак янында”, “Аю өнендә”, “Күрү ноктасы”, “Шагыйрь өчен табигать — серле һәм җанлы дөнья”, “Кызык һәм көлкеле хәлләр” бүлекләренә дәреслек-хрестоматиянең “Хайваннар турындагы һәм тылсымлы әкиятләр”, “ Фантазия һәм ялган”, “Чын һәм ялган байлык турында”, “Күрү ноктасы”, “Табигатьтә һәрнәрсә матур”, “Көлкеле хәлләр сере” бүлекләре туры килә.

Дәреслек һәм мөстәкыйль эш дәфтәре дә бер үк максатларны тормышка ашыра.

**Укыту методик комплектының үзенчәлекле яклары**

Укыту методик комплектының төп үзенчәлекләренең берсе булып төрле төсләр белән билгеләү, аерым өлешләрне күрсәтү тора.(сюжет элементларын, әхлакый-эмоциональ мәгънәләрен ачыклау өчен) Мәсәлән : Г. Тукайның "Кәҗә белән Сарык әкияте"ндә чылбыр буенча уку мәгънәви кисәкләргә бүлеп бирелде (текст кырында сары һәм зәңгәр төсләр), Ә текст кызыл сызыклар белән бүлекләргә аерылды. Балаларда рольләргә бүлеп уку күнекмәсе камилләштерү максатыннан туры сөйләм сары һәм зәңгәр сызыклар белән әйләндереп алынды, текст эчендә бала игътибар итәргә тиешле сүзләр кара хәрефләр белән күрсәтелде. Аерым әсәрләрдә (мәсәлән,"Ник соң әле итек җитмәде",..) кабатлаулар зәңгәр төс белән бирелде. Мөстәкыйль эш дәфтәрендә дә балалар ике төрле карандаш белән эшлиләр. Күбесенчә сары төс уңай эмоцияләрне, ә зәңгәр төс курку, борчылу һ.б. белдерә. Кайбер очракта баланың үзенә сайлап буяу мөмкинлеге бирелә. Бер үк текст өстендә төсләр белән дә, төрле тамгалар белән дә эш оештырыла.

**Программаны үтәү өчен кулланыла торган әдәбият:**

Сафиуллина Г. М. һ.б. Әдәби уку 1-4 сыйныф: Дәреслек. 2 кисәктә — К. : Мәгариф — Вакыт нәшрияты, 2012, 2017
Сафиуллина Г. М. һ.б. Әдәби уку 1-4 нче сыйныф: Дәреслек-хрестоматия. — К. : Мәгариф — Вакыт нәшрияты, 2012,2017
Сафиуллина Г. М. һ.б. Әдәби уку: Мөстәкыйль эш дәфтәре. 1-4 сыйныф — К. : Мәгариф — Вакыт нәшрияты, 2012,2017
Сафиуллина Г. М. һ.б. Әдәби уку 1-4 нче сыйныф: Методик кулланма. — К. : Мәгариф — Вакыт нәшрияты, 2012, 2017

## "Әдәби уку"дәреслегенә методик аңлатмалар. 3нче сыйныф

Әдәби уку курсында һәр уку елының үзенең аерым үзенчәлекләре бар. Бу фәнне укытуның төгәл бурычлары программа таләпләрендә ачык чагыла.

Өченче сыйныф программасы балаларны борынгы жанрлар: хайваннар турында әкиятләр, мәсәлләр, мәкальләр белән таныштыра. Бу уку елы халык авыз иҗатыннан авторлар әсәрләренә күчү чоры булып тора. Төрле жанрлар арасындагы аермалар тирәнрәк өйрәнелә. Балаларның уку күнекмәләре киңәя. Анализ өчен төп әдәбият булып элеккечә үк хәзерге балалар әдәбияты һәм классик әсәрләр кала. Шул ук вакытта рус һәм чит ил язучылары әсәрләре белән дә танышу бара. Бүгенге балалар әдәбияты белән таныштыру да бик мөһим, чөнки ул балаларның һәм өлкәннәрнең бүгенге яшәү рәвешенә якын. Сынлы сәнгать әсәрләре белән танышу дәвам итә. Алар темалары һәм эчтәлекләре белән шул әдәби әсәргә бик якын булалар. Программа поэтик форманың кайбер әһәмиятле үзенчәлекләре белән таныштыруны күз алдында тота. Укучылар, махсус терминнар кулланмыйча гына, парлы һәм арадаш рифмаларның дөрес яңгырашын, эчтәлеккә йогынтысын бәяли алачаклар. Төрле рифмаларның чиратлашуы аша ритм төшенчәсе дә бирелә.

Өченче сыйныфны тәмамлаганда укучылар әдәби процессның хәрәкәтен күзалларга, төрле халыкларның әдәбиятлары үсешенең тамырлары бер булуын төшенергә, әдәби образның прозада һәм поэзиядә үзенчәлекле кичерешләрен аңларга тиешләр.

Әдәби уку дәресләре программасы, 3 нче сыйныф

**Хайваннар турында әкиятләр.** Халык авыз иҗатының бер төре булган һәм җир йөзендәге барлык милләтләрдә дә яшәп килүче, буыннан буыннарга күчеп йөрүче хайваннар турындагы әкиятләр турында гомуми күзаллау булдыру. Әкиятләрнең гасырлар дәвамында үсеше. Гади вакыт тасмасы: 1) бик борынгы әкиятләр, 2) борынгы, 3) бик борынгы булмаган әкияти вакыйгалар турында аңлату.

Бик борынгы әкиятләрдә хайваннар арасындагы мөнәсәбәтләр, аларның тышкы күренешләре төп урынны алып тора. Борынгы әкиятләрдә геройның аңы, хәйләгә осталыгына дан җырлана. Ә әкияти вакыйгалар исә үз эченә геройның изге эшләрен, аның сәләтен, киң күңеллеген күрсәтүне максат итеп куя. Йөремсәк әкиятләр турында кузаллау булдырыла.

**Мәсәлләр жанры.** Мәсәлләрнең ике өлештән: хикәяләү (тарихи вакыйга) һәм мораль (нәтиҗә, тәрбияви аңлатулар) торуын аңлату. Мәсәлнең хикәяләү өлешенең әкиятләрдән килеп чыгуына басым ясау. Мәсәлләрнең мораль өлешенең мәкальләр белән охшашлыгы. Мәсәл жанрының килеп чыгышы, үсеше. Бөтендөньяга танылган мәсәлчеләр: Эзоп, Ж. Лафонтен, И. Крылов, татар мәсәлчеләре К. Насыйри, Г. Тукай, М. Гафури, Т. Яхин, Г. Шамуков, Ә. Исхак, Ф. Яхин һәм башкалар турында өйрәнү.

**Мәкаль жанры.** Мәкальләр – ул борынгылар сүзе, аталар сүзе, картлар сүзе, тәҗрибә һәм хикмәт җимеше, хәтердә сакланырга тиешле хәзинә, халыкның күмәк фикере, тормыш кагыйдәсе, сүзгә дәлил, тормышта киңәш. Мәкаль сүзе гарәп теленнән алынган, “урынлы сүз якитиешле урында әйтелгән сүз” дигән мәгънәне аңлатуын төшендерү. Төрле халыклар мәкальләре. Мәкальләрне сөйләмдә, мәсәлләрдә урынлы куллану.

**Хикәя жанры турында кузаллау формалаштыру.** Хикәя геройлары, аларның портретлары һәм характер үзенчәлекләре, башкарган гамәлләре аша чагылышы. Авторның үз героена мөнәсәбәте. Геройларга чагыштырма характеристика. Герой яшәгән тирәлек, пейзаж.

**Әкият һәм хикәя жанрының үзгәлеге турында кузаллау формалаштыру.** Әкият һәм хикәя жанрларының композиция үзенчәлеген (күзәтүләр аша) аңлату. Укучы-тыңлаучыга табигый көчләрнең серен, әкият геройларының серле тормыш агышын күрсәтү, хикәя геройларының характерын тормыштан алынган вакыйгаларны чагылдырып сөйләү.

**Шигърият.** Кеше һәм табигать бергәлеге. Дөньяны шагыйрь күзлегеннән чыгып кузаллау. Әйләнә-тирә дөньяның матурлыгы — шагыйрь өчен илһам чишмәсе булуга инандыру. Шигырьдә чагыштыру, сынландыру, эпитет. Автор әсәрләрендә һәм халык авыз иҗатында охшашлык. Чагыштыру, контраст, җанландыру кебек гади әдәби алымнарны таба белү. Җанлы сөйләмнең мөһим чараларын үзләштерү күнегүләре: темп, тавыш көче, тон, сөйләм мелодикасы (*тавышны күтәрү, түбәнәйтү*).

**Вакыт тасмасы**. Фольклор әсәрләреннән әкиятләрне вакыт тасмасында күрсәтү(*бик борынгы, борынгы, әкияти вакыйгалар*)

**Библиографик культура формалаштыру.**

“Эчтәлек ” белән танышу , аңа карап, кирәкле әсәрне китаптан таба белү, кече яшьтәге мәктәп баласының дәреслектән тыш эшчәнлеген оештыру: өй, мәктәп китапханәләреннән файдалану. Фән буенча сүзлек, белешмә әдәбият, вакытлы матбугат белән эшләү. Балалар китабы белән эшләү. Китапның төп элементларын аеру: китап тышлыгы, китап төпсәсе, битләре. Китапны саклап тоту күнекмәләре булдыру. Төрле җыентыклар төзергә өйрәнү.

**Уку, сөйләү, тыңлау күнекмәләре формалаштыру**

Сәнгатьле уку күнекмәләре формалаштыру (интонация, тон, темп саклап кычкырып уку) Автор бирергә теләгән картинаны күзаллау. Эчтән укый белергә күнектерү. Чылбыр рәвешендә укыганда үз урыныңны белеп , чират буенча уку.Укылган әсәргә анализ ясау. Уку техникасын үстерү

**3 нче сыйныфны тәмамлаганда укучыларның белеменә, эш осталыгына, һәм күнекмәләренә таләпләр.**

— әсәрне сүзләрне дөрес әйтеп кычкырып һәм эчтән укый белү;
— әсәрнең мәгънәви кисәкләре арасындагы бәйләнешләрне ачыклау, төп фикерне билгеләү һәм аны үз сүзләрең белән әйтеп бирү;
— төрле авторларның 6-8 шигырен яттан сөйләү;
— кыска күләмле әсәрләрнең эчтәлеген сөйләү;
— тылсымлы һәм хайваннар турындагы әкиятләрне, мәсәлләрне аера белү;

— әсәрдәге төп геройны характерлау, төрле әсәр геройларына чагыштырма характеристика ;
— укылган әсәрдән чагыштыру, җанландыру, контрастны таба белү;
— сүзлекләрдән файдалану;
—элементы буенча китапта ориентлашырга өйрәтү (*авторы, исеме, “Эчтәлек” бите, иллюстрацияләр)*

**“Әдәби уку” дәреслегенә методик аңлатмалар**

**Искәрмәләр**

1**. Аңлатмалы сүзлек, фразеологик әйтелмәләр сүзлеге** һәр дәреслекнең, дәреслек-хрестоматиянең һәм мөстәкыйль эш дәфтәренең ахырында бирелә.

2.“**Музей йорты”**на сәяхәт вакытында укучыларның сөйләм телләрен, күзәтүчәнлекләрен, матурлыкка соклана белү хисләрен, гади генә предметны да образ итеп күрә белүләрен үстерергә кирәк.

3.Мөстәкыйль эш дәфтәре белән эш вакытында укучы сары һәм зәңгәр **төсле карандашлар, гади карандаш** белән эш итә (фломастерлар белән түгел).

4. Әдәби уку дәресләренең кайберләрендә,”Музей йортына ” сәяхәт вакытында сәнгать әсәрләренең аерым детальләрен яхшылап күзәтү өчен, **лупа** кулланыла.

5.“Музей йорты” белән танышкан вакытта, картиналардан аеруча әһәмиятле фрагментларны кадрлап аерып алу һәм аларны бербөтен итеп карау өчен билгеле бер размердагы рамкалар файдаланыла. Бу рамкаларны технология дәресләрендә картоннан яисә калын кәгазьдән ясарга мөмкин. Рамканың соргылт, яшел, караңгы төстә булуы мөһим (ак төстә түгел). Рамка 6 см х 9 см зурлыкта була һәм һәр яктан 1,5 см поля калдырып эшләнелә.

6. Дәрес өчен материал күп бирелде, Көчле укучылар белән эш оештыру өчен укытучының барлык мөмкинлекләре дә бар. Һәрбер чыганакта да (дәреслек, хрестоматия, мөстәкыйль эш дәфтәре) җитәрлек әсәрләр сайланды. Укытучы өстәмә әсәрләр эзләп мәшәкатьләнмәсә дә була. Күрсәтелгән барлык материалларны эшләп бетерү мәҗбүри түгел, сыйныфның хәзерлек дәрәҗәсенә карап, укытучы үзе сайлап ала. Дәрестә бирелгән материал күп дип уйлаганда мөстәкыйль эш дәфтәрендәге биремнәрне калдырып, материал аз дип уйланган дәресләргә өстәсәң, яисә өй эше итеп төрле хәзерлектәге укучыларга сайлап бирсәң дә була.

7. Автор әсәрләре ел фасыллары белән туры килмәскә мөмкин. Бу концепциядә бирелгән кабатлауларга кире кайтып эшләү мөмкинлеге бирү өчен махсус сайланды.

8. Сәнгать әсәрләренең берсе булган музыка белән танышу, аны әдәби һәм сынлы сәнгать әсәрләре белән чагыштыру.

**Укыту методик комплектының бурычлары**

“Әдәби уку” укыту методик комплекты түбәндәге мәсьәләләрне хәл итә:

1. “Перспектив башлангыч мәктәп” комплекты чишәргә тиешле гомумдидактик бурычлар: укучы үзенә кирәкле информацияне “Эчтәлек” битенә карап таба белергә; исеме буенча текстның эчтәлеген кузалларга; күзәтү эшчәнлеген формалаштырырга (*әдәби һәм сәнгать әсәрләреннән аерым детальләрне таба, барлык ваклыклары белән сөйләп бирә*) һәм гомумиләштерергә *(аерым детальләргә нигезләнеп таралган төрле мәгълүматларны берләштереп, бербөтен картина тудырырга)*, “акыллы өлкәннәр” белән хат аша аралашу ихтыяҗы формалаштырырга.

2. Бала яшенә туры килә торган теоретик бурычлар:

а) хайваннар турындагы әкият үзенчәлекләре белән таныштыру: татар халык әкиятләренең, бер яктан, башка халыкларның хайваннар турындагы әкиятләренә охшаш булуы (*төп геройлары — хайваннар, еш кына бер үк төрле мөнәсәбәтләргә керәләр)*, икенче яктан бер-берсеннән аерылалар *(төп геройлар башка төрле хайваннар, бер-берсе белән мөнәсәбәтләре бөтенләй башка төрле);* хайваннар турындагы автор әкиятләренең еш кына халык әкиятләренә нигезләнүе *(башлангыч сыйныфларда әле автор әкиятләренә нигезләнүе термин буларак әйтелми)*; халык әкиятләрендә аерым хайваннарның патшалык итүе *(баш булуы)*; хайваннар турындагы әкият героеның һәрвакыт көчсезләрне яклаучы гына түгел, еш кына хәйләкәр, тиктормас, көлкегә калучы икәнлеге турында төшенчә бирү;

ә) әхлакый бурычлар: күзәтүчәнлек, хыяллана белүчәнлек, дуслар белн аралашу, ярата һәм яратыла белү — бу байлык һәм рухи кыйммәт икәнлеге турында кузаллау булдыру;

б) эстетик бурычлар: матурлык — ул сине чолгап алган тирәлек, бары тик аны күрә белергә кирәклеге турында төшенчә бирү;

в) сөйләм телен үстерү бурычлары:

3. Текстта ориентлаша белергә өйрәтү: әсәрләрне өлешләргә бүлү, кирәк урынны табып укып күрсәтү, хисләр белән белдерелгән өзекнең эчтәлеген ачыклау; әдәби әсәрләргә бәя биргәндә һәм сәнгать әсәрләрен караганда “синең” предметка карашың һәм бәяң – бу “синең” әсәрне аңлау идеяң икәнен җайлап төшендерү.

Дәреслек һәм дәреслек-хрестоматия, мөстәкыйль эш дәфтәре структуралары һәм идея эчтәлекләре буенча бер-берсенә бәйләнеп килә. Мәсәлән, дәреслекнең “Күзәтәбез һәм тәэсирләр белән уртаклашабыз”, “Чагыштыру серләренә төшенәбез”, “Кешеләрнең хыяллларын аңларга тырышабыз”, “Ярату турында”, “Хикмәтле тормыш тәҗрибәсе туплыйбыз”, “Көлке серләре”, “Герой ничек туа”, “Үткәннәрне һәм хәзергене чагыштырабыз” бүлекләренә дәреслек-хрестоматиянең һәм эш дәфтәренең шул ук бүлекләре туры килә.

Дәреслек һәм мөстәкыйль эш дәфтәре дә бер үк максатларны тормышка ашыра.

**Укыту методик комплектының үзенчәлекле яклары**

Укыту методик комплектының төп үзенчәлекләренең берсе булып төрле төсләр белән билгеләү, аерым өлешләрне күрсәтү тора.(*сюжет элементларын, әхлакый-эмоциональ мәгънәләрен ачыклау өчен*) Мәсәлән : Н. Гыйматдинованың “Болын патшасы” әсәрендә чылбыр буенча уку мәгънәви кисәкләргә бүлеп бирелде. Балаларда рольләргә бүлеп уку күнекмәсе камилләштерү максатыннан туры сөйләм башланганда беренче хәрефләр кара һәм зәңгәр төстә булса, ә автор сөйләме сары төс белән аерып бирелде. Мөстәкыйль эш дәфтәрендә дә балалар ике төрле карандаш белән эшлиләр, шулай ук гади карандаш та кулланыла. Күбесенчә сары төс уңай эмоцияләрне, ә зәңгәр төс курку, борчылу һ.б. белдерә. Кайбер очракта баланың үзенә сайлап буяу мөмкинлеге бирелә. Бер үк текст өстендә төсләр белән дә, төрле тамгалар белән дә эш оештырыла.

Укыту планында фәнне өйрәнүгә 1 сәгать бирелгән очракта укытучының сайлап алырга, яисә теге яки бу әсәрне өйрәнүгә вакытны үзенчә бүлү мөмкинлеге күздә тотыла.

**Программаны үтәү өчен кулланыла торган әдәбият:**

Сафиуллина Г. М. һ.б.  Әдәби уку 3 нче сыйныф: Дәреслек. 2 кисәктә — К. : Мәгариф — Вакыт нәшрияты, 2013.
Сафиуллина Г. М. һ.б.  Әдәби уку 3 нче сыйныф: Дәреслек-хрестоматия. — К. : Мәгариф — Вакыт нәшрияты, 2013.
Сафиуллина Г. М. һ.б.  Әдәби уку: Мөстәкыйль эш дәфтәре. 3 нче сыйныф  — К. : Мәгариф — Вакыт нәшрияты, 2013.
Сафиуллина Г. М. һ.б.  Әдәби уку 3 нче сыйныф: Методик кулланма. — К. : Мәгариф — Вакыт нәшрияты, 2013.

**4 нче сыйныф.**

**Дүртенче сыйныф** программасы балаларга әдәбиятның сүз сәнгате буларак башка сәнгать төрләре: сынлы сәнгать, музыка белән тыгыз мөнәсәбәттә булуын аңлатуны эзлекле рәвештә дәвам итә. Укучыга борынгы кешеләрнең, дөнья барлыкка килүен дөрес кузаллауларына ирешү максатыннан мифлар, легендалар аша гомумкешелекнең язу барлыкка килгәнгә кадәрге яшәеше аңлатыла. Төп үзенчәлек булып кешенең табигать шартларына бәйлелеге тора. 3-4 сыйныф дәреслекләре төрле халыкларның фольклор, автор әсәрләре аша әдәбият-сәнгать бердәмлеген, аларның бербөтен булуын кузалларга ярдәм итә. Әгәр укучы шуны аңлый алса, ул төрле милләт фольклор әсәрләренең төп чыганагы бер үк табигать, безне чолгап алган дөнья икәнлеген аңлый, әдәби җәүһәрләрнең кыйммәтләре уртак булуын төшенә, үз милләтенең фольклор һәм әдәби мирасының дөньякүләм әһәмиятен аңлый алачак. Бу уку елы халык авыз иҗатыннан авторлар әсәрләренә күчү чоры булып тора. Төрле жанрлар арасындагы аермалар тирәнрәк өйрәнелә. Балаларның уку күнекмәләре киңәя. Анализ өчен төп әдәбият булып элеккечә үк хәзерге балалар әдәбияты һәм классик әсәрләр кала. Бүгенге балалар әдәбияты белән таныштыру да бик мөһим, чөнки ул балаларның һәм өлкәннәрнең  бүгенге яшәү рәвешенә якын. Сынлы сәнгать әсәрләре белән танышу дәвам ителә. Алар темалары һәм эчтәлекләре белән шул әдәби әсәргә бик якын булалар. Программа поэтик форманың кайбер әһәмиятле үзенчәлекләре белән таныштыруны күз алдында тота. Укучылар, парлы һәм арадаш рифмаларның  дөрес яңгырашын, эчтәлеккә йогынтысын бәяли алачаклар. Төрле рифмаларның чиратлашуы аша ритм  төшенчәсе дә бирелә.

**Дүртенче сыйныф** дәреслекләренең төп үзенчәлеге төп һәм урта мәктәп программасын җиңел үзләштерү өчен җирлек әзерләү. Фольклор һәм автор әсәрләренең төрле жанрларын анализлый һәм әсәргә бәя белергә  өйрәтү. Фольклор текстлар (тылсымлы әкиятләр һәм мифлар, легендалар) аша тарихи материаллар белән — төрле атамалар, кешеләрнең тормыш-көнкүреше белән таныштыру. Әдәби әсәрләрдәге хәрәкәт үсешен тоемларга җирлек хәзерләү, үзләренә кадәр яшәгән яшьтәшләренең тормышы белән танышу.  (19 нчы гасыр ахыры), шул чорның үзенчәлекле якларын күрсәтү. Дәреслекнең икенче төп максаты — кече яшьтәге мәктәп баласына авторларның күзәтүләре, алар чагылдырган фикерләрне аңлый һәм үз фикерләрен әйтә белергә, өйрәтү.  “Мин үзем” — укучы менә шушы максатка омтылып яшәсен.

Поэтик текстлар укучы аңына барып җитәрлек, сәнгатьле итеп укый алырлык, анализлый һәм ритм, рифмаларны дөрес аера алырлык булырга тиеш.

Укучы зур күләмле әсәрләрне дә ашыкмыйча, геройлар белән бергә яшәп, алдагы эпизодлар белән бәйли белеп укырга омтылсын, автор фикерләренә үз бәясен бирә белсен.

Дәреслек-хрестоматия әдәби әсәрләрнең төрлелеген арттыру өчен (дәреслек еш кына хрестоматиягә мөрәҗәгать и) хезмәт итә. укучыларны мөстәкыйль белем алырга хәзерли.

“Музей йорты” дәреслек куйган максатларны тормышка ашырырга ярдәм итә.

Дүртенче сыйныфны тәмамлаганда укучылар әдәби процессның хәрәкәтен күзалларга, төрле халыкларның әдәбиятлары үсешенең тамырлары бер булуын төшенергә, әдәби образның прозада һәм поэзиядә үзенчәлекле кичерешләрен аңларга тиешләр.

**Әдәби уку дәресләре программасы, 4 нче сыйныф (34 сәг)**

**Халык авыз иҗаты**

**Мифлар турында гомуми кузаллау булдыру.** Борынгы халыкларның тормышы, кеше һәм табигать арасындагы мөнәсәбәт. Тормыш агачы, тотем хайваннар һәм тотем үсемлекләр, кешеләрнең аларга карашы, борынгы традицияләрнең сакланышы.

**Тылсымлы әкиятләр.**

Дөнья турында борынгы кузаллаулар чагылышы. Тылсымлы әкият герое. Тылсым дөньясы, тылсымлы предметлар, сихри саннар, сүзләр, тылсымлы булышчылар. Тылсымлы әкият законнары: әкият герое өеннән чыгып китә, максатка ирешү юлы (тылсым дөньясы, карурманнар аша үтүче юл, сынаулар, тылсымлы булышчы ярдәме, җиңү шатлыгы). Халыклар әкиятләренең мифлар, легендаларда чагылышы.

**Риваять һәм легендалар.**

Риваять һәм легендаларда сөйләнгән геройлятьар, аларның кичерешләре. Тарихи бәйләнеш. Төрле атамалар, аларның килеп чыгышы. Риваять һәм легендаларда бирелгзн вакыйгаларның әкиятләрдә чагылышы.

**Автор әкиятләре**

Автор әкиятләренеңхалык әкиятләре белән охшашлыгы. (жанр һәм сюжет). Халык әкиятләрендәге тылсым белән җиңүләр, автор әкиятләрендә акыл белән эш итеп уңышка ирешү, ярату һәм яратыла белүнең көче.

**Фольклор жанрының тормышта, хәзерге вакытта яшәеше.**

Халык традицияләре һәм бәйрәмнәре. Гимннар (Татарстан гимны). Халык һәм автор әкиятләре.

**Хикәя**

Хикәя жанры турында кузаллау формалаштыруны дәвам итү**.** Хикәя геройлары, аларның портретлары һәм характер үзенчәлекләре, башкарган гамәлләре аша чагылышы. Авторның үз героена мөнәсәбәте. Геройларга чагыштырма характеристика. Герой характерының катлаулылыгы, вакыт белән бәйләнеше. Герой яшәгән тирәлек, пейзаж. Хикәядәге чынбарлык чагылышы. Әдәби тел берәмлекләре.

**Әкият һәм хикәя жанрының үзгәлеге турында кузаллау формалаштыру.** Әкият һәм хикәя жанрларының композиция үзенчәлеген (күзәтүләр аша) аңлату. Укучы-тыңлаучыга табигый көчләрнең серен, әкият геройларының серле тормыш агышын күрсәтү, хикәя геройларының характерын тормыштан алынган вакыйгаларны чагылдырып сөйләү.

**Шигърият.** Кеше һәм табигать бергәлеге. Дөньяны шагыйрь күзлегеннән чыгып кузаллау. Әйләнә-тирә дөньяның матурлыгы — шагыйрь өчен илһам чишмәсе булуга инандыру. Шигырьдә чагыштыру, сынландыру, эпитет. Автор әсәрләрендә һәм халык авыз иҗатында охшашлык. Чагыштыру, контраст, җанландыру кебек гади әдәби алымнарны таба белү. Җанлы сөйләмнең мөһим чараларын үзләштерү күнегүләре: темп, тавыш көче, тон, сөйләм мелодикасы (тавышны күтәрү, түбәнәйтү).

**Әсәр авторлары турында**

Шагыйрь, язучы, рәссамнарның биографиясе.

а) әсәрдә авторлар кичереше;

ә) автор күзәтүләренең чагылышы;

б) хәзерге заман авторлары белән очрашу, балаларның авторга сораулары, җаваплар.

**Библиографик культура формалаштыру.**

“Эчтәлек ” белән танышу , аңа карап, кирәкле әсәрне китаптан таба белү, кече яшьтәге мәктәп баласының дәреслектән тыш эшчәнлеген оештыру: өй, мәктәп китапханәләреннән файдалану. Фән буенча сүзлек, белешмә әдәбият, вакытлы матбугат белән эшләү. Балалар китабы белән эшләү. Китапның төп төп элементларын аеру: китап тышлыгы, китап төпсәсе, битләре. Китапны саклап тоту күнекмәләре булдыру. Төрле җыентыклар төзергә өйрәнү. Әсәр авторлары турында мәгълүмат туплау.

**Уку, сөйләү, тыңлау күнекмәләре формалаштыру**

Сәнгатьле уку күнекмәләре формалаштыру (интонация, тон, темп саклап кычкырып уку) Автор бирергә теләгән картинаны күзаллау. Эчтән укый белергә күнектерү. Чылбыр рәвешендә укыганда үз урыныңны белеп , чират буенча уку. Укылган әсәргә анализ ясау. Уку техникасын үстерү.

**4 нче сыйныфны тәмамлаганда укучыларның белеменә, эш осталыгына, һәм күнекмәләренә таләпләр.**

— әсәрне сүзләрне дөрес әйтеп кычкырып һәм эчтән укый белү;

— әсәрнең темасын, төп мәгънәсен ачыклау, мәгънәви кисәкләргә бүлү, алар арасындагы бәйләнешләрне, төп фикерне билгеләү һәм аны үз сүзләрең белән әйтеп бирү;

— фольклор жанрларын аеру: хайваннар турындагы, тылсымлы әкиятләрне өйрәнү, мәсәл, хикәя, турында кузаллау, халык иҗаты әсәрләре һәм автор әсәрләрен төркемли белү;

— әсәр геройларын характерлый белү, авторның үз героена мөнәсәбәтен күрсәтү, геройларга чагыштырма характеристика бирү;

— төрле авторларның 6-8 шигырен яттан сөйләү;

— кыска күләмле әсәрләрнең эчтәлеген сөйләү;

— укылган әсәрдән чагыштыру, җанландыру, контрастны таба белү;

— сүзлекләрдән файдалану, тематик сүзлекләр төзү;

— аерым әсәрләргә аннотация төзү;

— элементы буенча китапта ориентлашырга өйрәтү (авторы, исеме, “Эчтәлек” бите, иллюстрацияләр)

**Укучы белергә тиеш:**

— 4-5 татар, рус, чит ил классикларының исемен, аларның әсәрләрен;

— 1-2 балалар журналы һәм газетасының исемен, алрдагы рубрикаларны;

— 4-5 хәзерге заман язучы яки шагыйренең исемен, алар язган әсәрләрне һәм эчтәлеген;

— үзенә иң ошаган авторның берничә әсәрен.

**Алынган белемнәрне көндәлек тормышта куллану.**

— китапның төрле элементларына карап эчтәлеген билгеләү;

— китапханәдә мөстәкыйль рәвештә уку өчен китап сайлау;

— укылган әсәр геройларын тасвирлап сөйләү;

— төрле чыганаклардан кирәкле мәгълүматны табу;

1 нче класс

**Дәрес материалының тематик бүленеше (укыту планында <u>әдәби уку фәненә 1 сәгать</u> вакыт бирелгәндә)**

| № | Дәрес темасы | Дәреслек материалы | Хрестоматия материалы | Мөстәкыйль эш дәфтәрендә |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Сәяхәт башы<br>Аптыраткыч әкиятләр сере | Дәреслек белән танышу<br>“Саескан” әкияте | хрестоматия белән таныш-тыру.<br>.Ф. Яруллин “Саескан” | Сәяхәт башы<br>Аптыраткыч әкиятләр сере |
| 2 | Санамыш серләре<br><br><br>Борынгы санамышлар | Санамышлар<br>Борынгы санамышлар | “Мактанчык бака” әкияте<br>Борынгы санамышлар | Санамыш серләре<br>Борынгы санамышлар |
| 3 | Табышмак ничек төзелә? | Табышмаклар | Мөҗәһитнең балык турындагы табышмаклары | Табышмак ничек төзелә? |
| 4 | Эндәшләр | Эндәшләр | | Эндәшләр |
| 5 | Тизәйткечләр | Тизәйткечләр | Тизәйткечләр | Тизәйткечләр |
| 6 | Охшаш яңгырашлы сүзләр | 1. “Кайтаваз мәгарәсе” тексты,<br>2. М.Галиев “Кайтаваз”,<br>3. Ш.Галиев “Чагу”, “Таяк”, | | Охшаш яңгырашлы сүзләр |


ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | 4. Р. Газизов “Беләсезме” шигыре | | |
| 7 | Рифма һәм шигырь мәгънәсе | 1.Л.Лерон “Буталмышлар илендә”,<br>2.Р.Корбан ”Көчек”,”Яңгыр яуганда” | | Рифма һәм шигырь мәгънәсе |
| 8 | Шаян шигырьләр | Л.Лерон “Сабантуй галә-мәтләре” | Ф.Яруллин “Хыялый чебеш” | Шаян шигырьләр |
| 9 | Чылбыр әкиятләр | 1. “Аю белән өч кыз” әкияте,<br>2. Х.Халиков “Бии белмәгән аю” шигыре | “Песәй” әкияте | Чылбыр әкиятләр |
| 10 | Поэзиядә һәм прозада сүзләрнең үзенчәлекле яңгырашы | 1. Р.Бәшәр “Бал корты”, “Авазлар”,<br>2. Ф.Яруллин “Черкиләр җыры”.<br>Э.Шәрифуллина “Бәйрәм ашы – кара-каршы” | 1. Р.Бәшәр “Авылга кайту”,<br>2. Бөҗәкләр турындагы табышмаклар<br>Р.Фәйзуллин “Хыял” | Яңгыравык шигырьләр<br>Поэзиядә һәм прозада сүзләрнең үзенчәлекле яңгырашы |
| 11 | Урман мәктәбендә | 1. Х.Халиков “Әллә ул да белә микән?”,<br>2.Дару үләннәре турында шигырьләр. | Р.Вәлиева “Урман әкияте”. | Урман мәктәбендә |
| 12 | Малайлар, кызлар турында | 1. Р.Миңнул лин “Үзебез генә калгач”<br>2. Ш. Галиевның “Шауламагыз әти йоклый” шигыре | 1.Р.Миңнуллин “Малайлар бәйрәме иде”,<br>2. Х.Халиков “Кушамат”,<br>3. Ф.Зыятдино-ва “Мин андый малай түгел”,<br>4. Ф.Мөслимо-ва “Хәйләкәр каләм”, | Малайлар, кызлар турында |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | 5.Йолдыз “Урынсызга әрләмә”. | |
| 13 | Шигырьдә юмор хисе | 1. Б.Заходер “Өтерне кайда куярга?” | Ш.Галиев “Курыкма, тимим”, “Шәвәли сере” | Шигырьдә юмор хисе |
| 14 | Язучы фантазиясе Дөньяны кем ничек күрә? | 1. Р.Кутуй “Төнге әкият”,<br>2.Р.Миңнуллин “Шүрәлесез урман”<br>1.Р.Хисмәтуллин “Хәерле иртә”,<br>2. Х.Халиков “Әгәр күрә белсәгез” | | Язучы фантазиясе. Дөньяны кем ничек күрә? |
| 15 | Шагыйрь нәрсә күрә,<br>нәрсә ишетә? | 1. Р.Вәлиева “Кыңгырау чәчәк”,<br>2. Х.Халиков “Тартар белән сөйләшү”, “Аксак кәҗә” | Р.Корбан “Сукмак”, “Шүрәле рәхмәт әйткән” | Шагыйрь нәрсә күрә,нәрсә ишетә? |
